**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Микулинского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

423306, Азнакаевский район,
с. Микулино, ул. Советская, д.74
тел.8(855-92)33-2-09
E-mail: Mikul.Azn@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге башкарма комитеты**

423306, Азнакай районы,
Микулино авылы, Совет урамы, 74
тел.8(855-92)33-2-09
E-mail: Mikul.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от «11» 10.2021 ел №24

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Микулино авыл җирлеге башкарма комитетының 29.07.2021 ел 18 номерлы «Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Микулино авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Микулино авыл җирлеге башкарма комитетының 29.07.2021 ел 18 номерлы «Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.5 пунктының 2 - 10 абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Регламентта федераль мәгълүмат адреслы системасының дәүләт адреслы реестрын алып баруга һәм эксплуатацияләүгә бәйле кулланыла торган төшенчәләр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Федераль мәгълүмати адреслы система турында һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 декабрендәге 1221 номерлы «Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләрен раслау турында» Федераль закон белән төгәл тәңгәлләштереп кулланыла.»;

1.2. 1.5 пунктының 11-17 абзацлары. 3-9 абзацлар дип санарга;

1.3. 2.6.1 пунктының 4-7 пунктчаларында «башкарма комитет» сүзен «төзелгән килешү нигезендә муниципаль районның җирле үзидарә органы яки башкарма комитет»сүзләренә алмаштырырга;

1.4. 2.6.1 пунктының 8 пунктчасында «Башкарма комитет» сүзен «төзелгән килешү нигезендә муниципаль районның башкарма комитеты яисә җирле үзидарә органы» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 2.6.4 пунктында «башкарма комитетның структур бүлекчәсе» сүзләрен «муниципаль районның җирле үзидарә органнары, башкарма комитет» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) игълан итәргә, шулай ук Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.».

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка игълан ителгәннән соң) үз көченә керә.

Башлык И.А.Такиулин